ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КРАСНОСЕЛЬСКИЙ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
422700, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Биектау тиемер юл станциясе поселогы, Совет урамы, 13

СОВЕТ КРАСНОСЕЛЬСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422700, Республика Татарстан, Высокогорский район,
п. ж/д ст. Высокая Гора, ул. Советская, 13

тел./факс 8(84365) 2-35-82, e-mail: Ksel.Vsg@tatar.ru

**КАРАР** **РЕШЕНИЕ**

**16 июнь 2023 ел** **№ 73**

## Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге Советының аерым карарларның үз көчләрен югалтуын тану турында

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законы, 2020 елның 11 июлендәге 1036 нчы номерлы «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең норматив хокукый актларының һәм норматив хокукый актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану, кулланучылар хокукларын яклау өлкәсендә федераль дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашырганда контроль буенча чаралар үткәргәндә үтәлә торган мәҗбүри таләпләр булган башкарма хакимиятнең федераль органнарының норматив хокукый актларын гамәлдән чыгару турында» Россия Федерациясе Хөкүмәте Карарының 1 нче кушымтасының 34 нче пункты нигезендә, Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге Советының муниципаль хокукый актларын гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге Советы

**КАРАР КЫЛДЫ:**

1. Үз көчләрен югалткан дип танырга:

- Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге Советының 2013 елның 31 маендагы 95 нче номерлы «Красносельский авыл җирлеге территориясендә гражданнарның тормышына, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә һәм әйләнә-тирә мохиткә зыян китерергә мөмкин булган җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү кагыйдәләре» карарын:
- Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге Советының 2014 елның 3 мартындагы 123 нче номерлы «2013 елның 31 маендагы 95 номерлы карары белән расланган Красносельский авыл җирлеге территориясендә гражданнарның тормышына, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә һәм әйләнә-тирә мохиткә зыян китерергә мөмкин булган җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү кагыйдәләрне туры китерү турында» карарын.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Биектау муниципаль районы, Биектау тимер юл станция поселогы, Совет урамы, 13 йорт адресы буеннча,Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге Башкарма комитеты бинасында урнашкан мәгълүмат стендында, Татарстан

Республикасы Биектау муниципаль районының мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адрес буенча «авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында»: http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырып халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Красносельский авыл җирлеге
Башлыгы урынбасары Р.Р. Никитенко